**ГЛАВА
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «01» апреленнән № 15

2023 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсында катнашу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 августындагы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 614 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселогы нигезендә төзелгән авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын уздыру буенча 2024 елның 28 мартындагы 1 номерлы оештыру комитеты утырышы беркетмәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча (алга таба - Конкурс) конкурс комиссиясен 1 нче кушымта нигезендә төзергә.

2. 2023 ел нәтиҗәләре буенчаТатарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсын әзерләү

һәм уздыру буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Конкурс комиссиясенә:

3.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 елның 29 августындагы 614 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләре тарафыннан грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибен җиткерергә.

3.2. Конкурсны әзерләү, оештыру һәм уздыру, нәтиҗәләр ясау буенча гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашырырга.

3.3. Конкурска тәкъдим ителгән эшләрне карап чыгуны һәм урынга чыгып тикшерү үткәруне гамәлгә ашырырга.

3.4. 2024 елның 05 апреленә кадәр конкурска йомгак ясарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык урынбасары Н.И. Попкова

Татарстан Республикасыи
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2024 елның «01» апрелендәге
15 номерлы карарына
1 нче кушымта

2023 ел нәтиҗәләре буенчаТатарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча конкурс комиссиясе составы

Конкурс комиссиясе рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Козлов Вячеслав Михайлович | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы |

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Попкова Надежда Ивановна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары |

Конкурс комиссиясе секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Лаврентьева Ольга Александровна | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Васильева Светлана Анатольевна | - | «Единая Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Яңа Чишмә җирле бүлеге башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Вафин Рәфис Сәлихҗан улы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Завалишина Наталья Александровна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы рәисе |
| Сердюк Нина Анатольевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясе рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасыи
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2024 елның «01» апрелендәге
15 номерлы карарына
2 нче кушымта

2023 ел нәтиҗәләре буенчаТатарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2023 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга грантлар бирүгә республика конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булып тормаган авыл җирлекләренә һәм шәһәр тибындагы поселокларга 2023 ел йомгаклары буенча грантлар бирүгә катнашу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы тарафыннан төзелә (алга таба - Конкурс).

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, муниципаль норматив хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү нәтиҗәләрен анализлау; Конкурска йомгаклар ясау һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү.

3. Комиссиянең вәкаләтләре

3.1. Комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләреннән һәм башка кызыксынган органнардан Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларын һәм Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча башка кызыксынган органнарны чакырырга;

Комиссия эшчәнлегенә кызыксынган башка органнар вәкилләрен җәлеп итәргә;

гамәлдәге законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

## 4. Комиссия составы

4.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана. Комиссия составына рәис, рәис урынбасарлары, секретарь һәм комиссия әгъзалары керә.

4.2. Комиссия рәисе:

Комиссия эшен аның бурычлары нигезендә оештыра;

Комиссия утырышы өчен урынны, вакытны һәм көн тәртибен билгели;

Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

4.3. Комиссия рәисе урынбасары комиссия рәисе булмаганда һәм аның йөкләмәсе буенча Комиссия утырышларын үткәрә.

4.4. Комиссия секретаре Комиссия утырышларында карау өчен сораулар исемлеген төзи һәм утырышлар беркетмәләрен рәсмиләштерә.

## 5. Комиссия эшчәнлеген тәртип һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

5.1. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән үзләре катнаша.

5.2. Комиссия утырышы әгъзаларының 50 %процентыннан да ким булмаган өлеше булган очракта хокуклы була.

5.3. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының 50 проценттан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия рәисе һәм секретаре кул куя.

5.4. Конкурс йомгаклары утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә җибәрелә.